СИШӘМБЕ
19 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 15 (6737)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ,

I.

Безнең гаскәрләр Миллеровоны, Алексеевканы, Коротоякны, Подгорноены, Курсавканы алдылар

17 нче январьда безнең гаскәрләр, каты сугыштан соң, МИЛЛЕРОВО шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар. Шәһәрнең чолганыштан чыгарга маташкан немецлар гарнизоны безнең гаскәрләр тарафыннан бөтенләй диярлек кырып бетерелде. Бик күп трофейлар кулга төшерелде, шулар арасында 15 самолет, складлар һәм төрле сугыш милекләре төялгән тимер юл составлары бар.

ВОРОНЕЖДАН көньяктарак һөҗүм итеп баручы безнең гаскәрләр АЛЕКСЕЕВКА шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен, КОРОТОЯК шәһәрен, ПОДГОРНОЕ район үзәген һәм тимер юл станциясен алдылар.

ТӨНЬЯК КАВКАЗДА безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, КУРСАВКА район үзәген һәм зур тимер юл станциясен алдылар.

II.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләрнең трофейлары

ЗАКАВКАЗЬЕ фронты гаскәрләренең төньяк группасы частьлары (Закавказье фронтына армия генералы иптәш И. В. ТЮЛЕНЕВ командалык итә) Төньяк Кавказда немец оккупантларына каршы сугышларда 1942 нче елның 25 нче декабреннан 1943 нче елның 16 нчы январена кадәр түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: самолетлар—35, танклар—314, төрле калибрдагы орудиеләр—372, минометлар—422, танкка каршы ата торган мылтыклар—396, пулеметлар—602, винтовкалар—10.000 нән артык, снарядлар—385.000, авиабомбалар—300.000, винтовка патроннары—3 миллион чамасы, автомашиналар—2.338, мотоцикллар—460, радиостанцияләр—28, паровозлар—8, товар вагоннары—1.020, шулардан снарядлар төялгән вагоннар—20, танкларга һәм автомашиналарга запас частьлар төялгән вагоннар—48, тимер юл платформалары—550, тимер юл цистерналары—70, пассажир вагоннары—80, кар чистартучылар—27, сугыш припаслары, корал һәм азык тутырылган складлар—70.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СССР Верховный Советы Президиумы *УКАЗЫ*

АВИАЦИЯ, АРТИЛЛЕРИЯ ҺӘМ БРОНЕТАНК ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ЮГАРЫ КОМАНДА СОСТАВЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ ХӘРБИ ДӘРӘҖӘЛӘР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА

СССР Верховный Советы Президиумының 1940 нчы ел 7 нче май Указына өстәмә итеп, авиация, артиллерия һәм бронетанк гаскәрләренә югары команда составы өчен түбәндәге хәрби дәрәҗәләрне билгеләргә:

1) Авиация Маршалы
2) Артиллерия Маршалы
3) Бронетанк гаскәрләре Маршалы

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
16 январь, 1943 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

АРМИЯ ГЕНЕРАЛЫ Г. К. ЖУКОВКА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ МАРШАЛЫ ДИГӘН ХӘРБИ ИСЕМ БИРҮ ТУРЫНДА

Армия генералы Георгий Константинович Жуковка Советлар Союзы Маршалы дигән хәрби исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
18 январь, 1943 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

АРТИЛЛЕРИЯ ГЕНЕРАЛ-ПОЛКОВНИГЫ Н. Н. ВОРОНОВКА АРТИЛЛЕРИЯ МАРШАЛЫ ДИГӘН ХӘРБИ ИСЕМ БИРҮ ТУРЫНДА

Артиллерия генерал-полковнигы Николай Николаевич Вороновка артиллерия маршалы дигән хәрби исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
18 январь, 1943 ел.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

Татарстан АССР хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, авыл һәм поселок **советларына** сайлауны 1943 нче елның декабрена кадәр кичектерергә һәм бу Советларның полномочиеләрен шул срокка кадәр озынайтырга.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре С. СӘЕТГӘРӘЕВ.

Казан, Кремль.
18 январь, 1943 ел.

Соңгы сәгатьтә

I.

ЛАДОГА КҮЛЕННӘН КӨНЬЯКТАГЫ РАЙОНДА БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘРНЕҢ УҢЫШЛЫ ҺӨҖҮМЕ ҺӘМ ЛЕНИНГРАД БЛОКАДАСЫН ӨЗҮ

Ладога күленнән көньяктарак урнашкан безнең гаскәрләр Ленинград шәһәрен чолгап алган немец-фашист гаскәрләренә каршы шушы көннәрдә һөҗүмгә күчтеләр.

Безнең гаскәрләрнең бурычы дошманның оборонасын җимерү һәм шулай итеп Ленинград блокадасын өзү иде.

Монда шуны күздә тотарга кирәк: Ленинградны күп айлар буена чолгап торган немецлар шәһәргә килү юлларында үзләренең позицияләрен көчле рәвештә ныгытылган районга әйләндергәннәр, анда бик күп тармаклы, озак вакытка исәпләп ясалган, бетонланган һәм башка төрле корылмалар системасы, танкка каршы һәм пехотага каршы бик күп сакда киртәләр булган.

Безнең гаскәрләрнең һөҗүме ике яктан барды: Нева елгасының көнбатыш ярыннан, Шлиссельбургтан көньяк-көнбатыштарак һәм көнчыгыштан—Ладога күленнән көньяктагы районнан.

Безнең гаскәрләр дошманның озак вакытка исәпләп төзелгән ныгытылган полосасын 14 километр эчкәрегә таба өзеп һәм Нева елгасын кичеп, каты сугышларның 7 көне эчендә, дошманның гадәттән тыш каты каршылык күрсәтүен җиңеп, ШЛИССЕЛЬБУРГ шәһәрен, ныгытылган зур пунктлардан МАРЬИНОНЫ, МОСКОВСКАЯ ДУБРОВКАНЫ, ЛИПКАНЫ, 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8 нче номерлы эшчеләр поселокларын, СИНЯВИНО станциясен һәм ПОДГОРНАЯ станциясен алдылар.

Шулай итеп, 7 көн дәвам иткән сугышлардан соң Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре 18 нче январьда бергә кушылдылар һәм шуның белән Ленинград блокадасын өзделәр.

Безнең гаскәрләрнең һөҗүме барышында немецларның 227 нче, 96 нчы, 170 нче, 61 нче пехота дивизияләре, 207 нче пехота дивизиясенең 374 нче пехота полкы, 5 нче тау-укчы дивизиянең 85 нче пехота полкы, 223 нче мотоотряд һәм 1 нче пехота дивизиясенең бер өлеше тар-мар ителде.

Тулы булмаган саннар буенча безнең гаскәрләр 1.261 солдатны һәм офицерны плен алдылар.

Сугышлар вакытында безнең артиллериябез һәм минометларыбыз дошманның 470 ныгытылган узелын һәм блиндажын, нык итеп ясалган 25 күзәтү пунктын җимерделәр, 172 артиллерия һәм миномет батареясын юк иттеләр һәм бастырдылар.

Түбәндәге трофейлар кулга төшерелде: 222 орудие, 178 миномет, 512 пулемет, 5.020 винтовка, алты көпшәле 4 миномет, 26 танк, 9 бронемашина, 17.300 кул гранатасы, 72 радиостанция, 2.200.000 патрон, 22.000 снаряд, 36.000 мина, 150 автомашина, 1.050 ат, 880 повозка, һәртөрле 40 склад.

Сугыш кырында немец солдатларының һәм офицерларының 13.000 нән артык үле гәүдәләре калды.

Дошманның оборона линиясен Ленинград фронтының генерал-полковник Л. А. ГОВОРОВ командалыгындагы көчләренең бер өлеше һәм Волхов фронтының армия генералы К. А. МЕРЕЦКОВ командалыгындагы көчләренең бер өлеше өзде.

Һәр ике фронтның хәрәкәтләрен берләштерүне Верховный Баш Командование Ставкасы вәкилләре Советлар Союзы маршаллары иптәш Г. К. ЖУКОВ һәм иптәш К. Е. ВОРОШИЛОВ тормышка ашырды.

Сугышларда генерал-лейтенант иптәш В. З. РОМАНОВСКИЙ һәм генерал-майор иптәш М. П. ДУХАНОВ гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

II.

КӨНЬЯКТА БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ТИМЕР ЮЛ СТАНЦИЯСЕ КАМЕНСКИНЫ, ДИВНОЕ, ЧЕРКЕССК ШӘҺӘРЛӘРЕН, ТИМЕР ЮЛ СТАНЦИЯСЕ КАМЕНКАНЫ АЛДЫЛАР

Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре ТӨНЬЯК ДОНЕЦ елгасын үтеп чыктылар, тимер юл станциясе КАМЕНСКИНЫ алдылар һәм КАМЕНСК шәһәрендә сугыш алып баралар.

Көньяк фронт гаскәрләре Маныч елгасын үттеләр һәм ДИВНОЕ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Воронеж фронты гаскәрләре итальяннарның 4 нче корпусын җимерделәр һәм тимер юл станциясе КАМЕНКАНЫ алдылар. Безнең гаскәрләр ОСТРОГОЖСК шәһәрен чолгап алдылар.

18 нче январьда кичкә таба Воронеж фронты районында плен алынган солдатлар һәм офицерлар саны 31.000 гә кадәр артты, шулардан 22.000 венгр, 7.000 итальян һәм 2.000 нән артык немецлар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр ЧЕРКЕССК шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ЛИЧНЫЙ СОСТАВЫНЫҢ КИЕМ ФОРМАСЫ

Шинель.



Советлар Союзы Маршалының мундиры



Генерал мундиры.



Генералның кителе.



Өлкән команда составының мундиры.



Урта команда составының мундиры



Урта команда составының гимнастеркасы



Кече команда составының мундиры



Рядовой составның мундиры



Рядовой составның гимнастеркасы



Өстә-Маршал фуражкасы.
Аста-генерал фуражкасы.



Җиңнәрдә петлицалар һәм чигешләр

Кызыл Армиянең личный составының кием формасын үзгәртүнең язма аңлатмасы

I. ШИНЕЛЬЛӘРДӘ ҖЫР ПЕТЛИЦАЛАРЫ

Шинельләрдә петлицалар (хәзергеләре урынына)—озынча, өч яктан кантланган, югарыгы башында төймәсе бар.

Петлицаның озынлыгы, тегелгәннән соң—9 сантиметр; канты белән бергә киңлеге—3,25 сантиметр; кантының киңлеге —0,25 сантиметр.

Петлица үзе—яшькелт (защитный), канты—погоннар канты төсле. Советлар Союзы маршалларының һәм генералларның петлицаларында кант алтын канительдән, медицина һәм ветеринария хезмәте генераллары петлицаларының канты көмеш канительдән.

Советлар Союзы маршаллары һәм генераллар өчен төймәләр—зур күләмдә, гербле; армиянең калган бөтен составы өчен—зур күләмдә, формалы. Төймәләр хаки төсендә.

II. ШИНЕЛЬЛӘРДӘ КӨНДӘЛЕК ПЕТЛИЦАЛАР

Шинельләрдә көндәлек петлицалар, үзләренең формалары, зурлыклары һәм төймәләренең урнашулары ягыннан—җыр петлицалары белән бер төрле. Кантларның материалы—приборный сукно.

Советлар Союзы маршалларының петлицалары кызыл төстә. генералларныкы — гаскәрләрнең төренә карап:

гомуми гаскәрләргә (пехотада, кавалериядә) — кызыл;
артиллериядә һәм танк гаскәрләрендә — кара;
авиациядә — күк;
техник гаскәрләрдә һәм интендантлык хезмәтендә — малиновый;
медицина һәм ветеринария хезмәтендә — куе яшел.

Петлицаларның канты—алтын канительдән. Медицина һәм ветеринария хезмәте генераллары петлицаларының канты—көмеш канительдән.

Петлицаларның төймәләре—зур, формалы, алтынланган һәм гербле.

Кызыл Армиянең барлык башка личный составы петлицаларының кантлары һәм петлицалар үзләре—гаскәрләрнең төрләренә (хезмәткә) карап:

пехотада
канты кара, үзе малиновый;
артиллериядә
канты кызыл, үзе кара;
автобронетанк гаскәрләрендә
канты кызыл, үзе кара;
авиациядә
канты кара, үзе күк;
кавалериядә
канты кара, үзе ачык зәңгәр;
инженер-техник гаскәрләрдә
канты кара, үзе кара;
интендантлык хезмәтендә

(Ахыры 3 нче биттә).

Кызыл Армиянең личный составының кием формасын үзгәртүнең язма аңлатмасы

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

канты кара, үзе малиновый;
медицина һәм ветеринария хезмәтендә
канты кызыл, үзе куе яшел;
хәрби юридик хезмәттә
канты кара, үзе малиновый.

Артиллерия һәм бронетанк гаскәрләренең бөтен команда составының петлицалары—бархаттан.

Төймәләре—зур формалы; команда составы петлицаларында—алтынланган; кече командирлар һәм рядовойлар составында—җиздән.

III. КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ЛИЧНЫЙ СОСТАВЫНЫҢ МУНДИРЛАРЫНДА ПЕТЛИЦАЛАР ҺӘМ ЧИГЕШЛӘР

А. СОВЕТЛАР СОЮЗЫ МАРШАЛЛАРЫ МУНДИРЛАРЫ

Мундир якасының югарыгы һәм алгы кырыйлары ике катлы алтын кант белән тегелгән.

Якаының алгы очларында, аның бөтен киңлегенә, алтын имән яфраклары чигелгән; мундир җиңнәренең очларында да аларның бөтен әйләнәсенә шундый ук чигеш ясалган.

Б. ГЕНЕРАЛ МУНДИРЫ

Мундир якасының югарыгы һәм алгы кырыйларына ике катлы алтын кант тегелгән.

Якаының алгы очларында, алтын кант буйлап, лавр ботагы төсендә тар алтын чигеш бар.

Җиң очларында бастырып куелган, алтын белән тегелгән 3 петлица (багана) ясалган.

Медицина һәм ветеринария хезмәте генералларының якаларында һәм җиң очларында чигешләр—көмеш.

В. ӨЛКӘН ҺӘМ УРТА КОМАНДА СОСТАВЫ МУНДИРЛАРЫ

Мундирларның якасында, алгы кырыйлардан 1 сантиметр эчкәрәк кертеп, кантсыз, приборный сукнодан озынча петлицалар тегелгән. Петлицаларның озынлыгы, тегелгән хәлдә—8,2 сантиметр, киңлеге 2,7 сантиметр.

Петлицаларның төсе гаскәрләрнең төренә карап:

пехотада — малиновый;
артиллериядә — кара;
автобронетанк гаскәрләрендә — кара;
авиациядә — күк;
кавалериядә — ачык зәңгәр;
инженер-техник гаскәрләрдә — кара;
интендантлык хезмәтендә — малиновый;
медицина һәм ветеринария хезмәтендә — куе яшел;
хәрби юридик составта — малиновый.

Өлкән команда составы петлицаларында—көмеш җеп белән үрелгән, алтын канитель белән тегелгән, ике озынча тасма. Урта команда составы петлицаларында—бер тасма.

Өлкән һәм урта инженер - команда составы һәм интендантлык, медицина һәм ветеринария хезмәте команда составы һәм хәрби юридик хезмәттәге начальниклар составы петлицаларында—команда составындагыча, алтын җеп белән үрелгән, ләкин көмеш канительдән ясалган ике яки бер тасма.

Өлкән команда составы петлицаларында тасмалар берсе өстенә икенчесе 0,5—1,0 миллиметр ара калдырып урнаштырылганнар.

Тасмаларның озынлыгы—5,4 сантиметр, киңлеге — 6,5 миллиметр.

Өлкән команда составы мундирларының җиң очларында — алтын белән тегелгән, бастырып куелган икешәр петлица (багана). Урта командa составында—берәр.

Инженер-команда составы һәм интендантлык, медицина һәм ветеринария хезмәтендәге команда составы һәм хәрби юридик хезмәттәге начальниклар составы өчен петлицалар (баганалар) көмеш белән тегелгәннәр.

Г. КЕЧЕ КОМАНДА ҺӘМ РЯДОВОЙЛАР СОСТАВЫ МУНДИРЛАРЫ

Мундирның якасында команда составы мундирларындагы шикелле петлицалар.

Кече команда составы петлицаларында буйдан-буйга 6 миллиметр киңлектә, алтынсыман төстәге ефәк галуннан эшләнгән бер озынча тасма. Стройдан тыш кече начальниклар составында бу тасма көмешсыман ефәк галуннан ясала.

Рядовой состав мундирларының петлицаларында бер нәрсә дә юк.

IV. СОВЕТЛАР СОЮЗЫ МАРШАЛЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ГЕНЕРАЛЛАРНЫҢ ФУРАЖКАЛАРЫ

Советлар Союзы маршалларының парад фуражкасының кырые алгы яктан имән яфраклары формасында алтын белән чигелгән.

Кызыл Армия генералларының парад фуражкалары кырыеның алгы өлешендә лавр ботаклары формасында алтын чигеш бар.

Медицина һәм ветеринария хезмәте генералларының фуражкалары кырыйлары куе яшел һәм кантлары кызыл төстә; көндәлек фуражкалардагы филигран—көмештән. Шулай ук парад фуражкалары кырыендагы чигешләр дә көмеш.

V. КИТЕЛЬЛӘР, МУНДИРЛАР ҺӘМ ГИМНАСТЕРКАЛАР

А. КИТЕЛЬ

Генераллар өчен—хәзерге үрнәктә, ләкин туры-кайтарма яка урынына өске кырыена кант ясалган, 4,5—4,8 сантиметр биеклектәге туры каты яка куела.

Китель җиңнәрендә билгеләр һәм петлицалар булмый, алар урынына иң башларына, билгеләнгән формада, погоннар куела.

Б. МУНДИР

Мундир хәзерге формада, ләкин туры-кайтарма яка урынына өске кырыена кант ясалган, 4,5—4,8 сантиметр биеклектәге туры каты яка куела.

Мундир җиңенең очы туры, кайтармасыз.

Советлар Союзы маршаллары һәм генераллар мундирларының якаларында һәм җиң очларында—алтын чигешләр.

Команда һәм начальниклар составы мундирларының якларында алтын яки көмеш чигеш белән петлицалар, җиң очларында—алтын яки көмеш чигешләр.

Кече командирлар һәм начальниклар составы мундирларының якаларында озынча алтынсыман яки көмешсыман тасма белән яңа формадагы петлицалар.

Рядовой состав мундирларының якаларында тасмасыз яңа формадагы петлицалар.

Кызыл Армиянең бөтен личный составының мундирларына җиңгә куела торган билгеләр урынына погоннар беркетелә.

В. СУКНОДАН ҺӘМ МАМЫК МАТЕРИЯДӘН ГИМНАСТЕРКАЛАР

Гимнастеркалар хәзерге формада, ләкин түбәндәге үзгәрешләр белән: барлык төрләрдәге гимнастеркаларның кайтарма якалары урынына алгы яктан кечкенә күләмдәге формалы ике төймәгә төймәләнә торган, йомшак, туры якалар.

Өске планка уртадан үтә һәм кечкенә күләмдәге, формалы өч төймәгә төймәләнә.

Иң башларына, билгеләнгән үрнәктә, погоннар куела.

Рядовой составның гимнастеркалары кесәсез. Начальниклар составы гимнастеркаларында хәзерге өстән куелган кесә урынына эчкә ясалган һәм каплавычлы кесәләр.

Шинельләрдә, мундирларда, кительләрдә һәм гимнастеркаларда җиңгә куела торган билгеләр бетерелә.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

17 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

17 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград районында, Воронеждан көньяктарак, Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы һәм Төньяк Донец районында элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында немец фашистларының чолганып алынган гаскәрләрен юк итүне дәвам иттерделәр. Заводлар районында безнең частьлар немецларга көчле удар ясадылар һәм күп кенә урамнарны чистарттылар. Сталинградның көньяк читендә Н-че берләшмә сугышчылары алга барып, дошман обороносының әһәмиятле биеклекләргә урнашкан һәм көчле рәвештә ныгытылган берничә оборона узелын алдылар. 600 гә якын гитлерчы, 6 танк һәм 17 орудие юк ителде. 298 пленный алынды. 94 пулемет, 200 гә якын автомашина, 3 радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

Сталинградтан көнбатыштарак безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, 1.200 немец солдатын һәм офицерын кырдылар. Кулга төшерелгән трофейлар арасында 28 танк, 60 орудие, 57 миномет, шулардан 6 көпшәле 2 миномет, 120 пулемет, 115 йөк автомобиле һәм 35 җиңел автомобиль бар.

* * *

Воронеждан көньяктарак безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүме дәвам итте. Донның уң як ярына дошман 6 ай буена оборона линиясе төзеп һәм аны ныгытып килгән. Һөҗүмгә күчкән совет частьлары немецларның көчле оборона системасын берничә сәгать эчендә җимерделәр, кальга кырларын һәм тимер чыбык киртәләрен үттеләр. Н-че часть сугышчылары, дошманны куып барып һәм юк итеп бер полк пехотасын тар-мар иттеләр. Һәм 16 орудие, 53 пулемет, 24 миномет, бер радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. 380 кеше плен алынды. Икенче бер участокта безнең танк һәм мотопехота подразделениеләребез халык яши торган зур бер пунктка бәреп керделәр. Ике арада башланып киткән сугышта дошман гарнизоны солдатларының шактый өлеше кырып ташланды. Калган немец солдатлары һәм офицерлары—барлыгы 530 кеше коралларын ташладылар һәм пленга бирелделәр. Күп кораллар, 2 сугыш припаслары склады, бер элемтә милекләре склады һәм 3 азык склады кулга төшерелде.

* * *

Зимовники районында безнең танк һәм пехота частьлары дошманны зур югалтуларга дучар иттеләр. 1.000 нән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырылды. Немецларның 26 танкысы юк ителде. Чигенгән чакта гитлерчылар бик нык каршылык күрсәтәләр. Халык яши торган бер пункт районында аеруча каты сугышлар булды. Бу пункт 5 тапкыр кулдан-кулга күчте һәм анда безнең гаскәрләр ныгып урнаштылар.

* * *

Төньяк Донец районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын зур югалтуларга дучар иттеләр. Немецларның 800 дән артык солдат һәм офицерлары үтерелде. Дошманның 12 танкысы һәм 30 орудиесе юк ителде. Күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Безнең танк частьларыбыз һәм моторлаштырылган частьлар дошман оборонасын ватып, халык яши торган берничә пунктны алдылар.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары дошманга каршы күп сәгатьләр дәвам иткән сугышта 200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырдылар. Немецларның 7 танкысы яндырылды һәм зарарланды. Икенче бер участокта командиры иптәш Железнов булган подразделениенең танкистлары дошманның бер терәк пунктына бәреп керделәр һәм бер рогата якын немец пехотасын юк иттеләр. Һава сугышларында һәм зенит артиллериясе уты белән немецларның 24 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Немецларның безнең частьларны тоткарларга маташулары уңышсыз чыкты. Безнең сугышчылар дошманның контратакаларын кире кайтарып һәм аның каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Моторлаштырылган Н-че часть 3 танк, 5 орудие һәм 60 автомашина кулга төшерде. Совет кавалеристлары немецларның тылына үтеп чыктылар һәм дошман обозын тар-мар иттеләр. 12 автомашина һәм сугыш припаслары төялгән 30 олау юк ителде.

* * *

Барановичи өлкәсендә хәрәкәт итүче Божейко исемендәге партизаннар отряды актив сугыш хәрәкәтләренең бер ае эчендә немецларның гаскәрләр, сугыш техникасы һәм сугыш припаслары төялгән 4 эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт вакытында 4 паровоз, солдатлар төялгән 12 вагон, танклар төялгән 8 платформа, сугыш припаслары һәм кораллар төялгән 32 вагон җимерелгән. Вилейка өлкәсендә хәрәкәт итүче «Буря» исемле партизаннар отряды 2 ай эчендә дошманның 3 хәрби эшелонын һәлак итүне оештырган. 2 паровоз, гаскәрләр һәм техника төялгән 18 вагон җимерелгән.

17 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

17 нче январьда безнең гаскәрләр каты сугыштан соң **Миллерово** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар.

Воронеждан көньяктарак һөҗүм итеп баручы безнең гаскәрләр **Алексеевка** шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен, Коротояк шәһәрен, **Подгорное** район үзәген һәм тимер юл станциясен алдылар.

Төньяк Донец районында безнең гаскәрләр халык яши торган берничә дистә пунктны, шул исәптән халык яши торган зур пунктлардан **Красновканы, Исаевканы, Верхне - Митякинскийны, Астаховны, Калитвенскаяны**, тимер юл станцияләреннән **Погореловоны, Красновканы** алдылар.

Орловская районында безнең гаскәрләр халык яши торган зур пунктлардан **Буденновскаяны, Бекетныйны, Донскойны, Ногаевско - Ребричанскийны, Гундоровны, Романовны**, тимер юл станцияләреннән **Эльмутны** һәм **Восточныйны** алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр кискен атака нәтиҗәсендә **Курсавка** район үзәген һәм зур тимер юл станциясен, район үзәге **Гафицкоены**, халык яши торган зур пунктлардан **Сергиевканы, Султанскоены, Кырым - Гиреевскоены, Воровско - Лесскаяны**, тимер юл станциясе **Крым-Гиреевоны** алдылар.

10 нчы январьдан 16 нчы январьга кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 265 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 133 самолет югалттык.

* * *

16 нчы январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 15 кә якын танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 50 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар. бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец фашистларының чолганып алынган гаскәрләрен кыруны дәвам иттерделәр. Совет частьлары, чолганыш боҗрасын кысып, тагын алга киттеләр. Сталинградтан көнбатыштарак безнең сугышчылар, немецларның таркатылган группаларының каршылык күрсәтүләрен җиңеп, алга баруларында дәвам иттеләр. Питомниктан төньяктарак булган бер аэродром өчен каты сугыш башланып китте. Немецлар безнең гаскәрләрне тоткарламакчы булдылар, ләкин безнең сугышчылар, омтылышлы атака ясап, аэродромга бәреп керделәр, блиндажларга яшеренгән гитлерчыларны кырдылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Орловская районында безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга баруларында дәвам иттеләр. Совет частьлары алга китеп, дошманның флангларына барып чыгалар, аның подразделениеләрен бер-берләреннән аералар һәм аларны өлешләргә бүлеп кыйныйлар. Н-че берләшмә частьлары бер көн эчендә халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта безнең танкистлар дошман батальонын тар-мар иттеләр һәм 400 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Бер танк, танкка каршы ата торган 9 орудие, 23 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Воронеждан көньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган дистәләрчә пунктларны алдылар. Бер участокта немецларның моторлаштырылган бер полкы тар-мар ителде, дошманның 17 танкысы һәм 8 бронемашинасы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 18 орудие һәм сугыш милекләре саклана торган 2 склад бар. Икенче бер участокта совет сугышчылары халык яши торган бер зур пунктта дошман гарнизонының каршылык күрсәтүен бастырдылар. 6 танк, бер бронемашина, 13 орудие, 40 пулемет, 46 автомашина һәм бер ягулык склады кулга төшерелде. 300 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

Ахыры 4 нче биттә.

„КОМБАЙН" КОЛХОЗЫНДА

ТЕЛӘЧЕ, 16 январь. (Телефон буенча). «Комбайн» колхозы члennaры язгы чәчүгә әзерлек эшләрен тизрәк тәгәлләү өчен үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Колхозчылар чәчүлек орлыкларын вакытында чистартып бетерүгә зур игътибар бирделәр. Хәзер барлык культуралар буенча да чәчүлек орлыклары чистартылып бетте. Алар коры урыннарда саклана лар. Орлыкларның тишелеше лабораториядә тикшерелә.

Агротехника чараларын үткәрү дә яхшы оештырылган. Басуга 762 йөк тирес чыгарылды, 125 гектар мәйданда кар тотылды. Бер көн эчендә генә дә 12 центнер көл җыелды. Көл һәм кош тизәге җыю дәвам итә.

Сабаннар, культиваторлар, сука камытлары, дилбегәләр барысы да ремонттан чыкты инде. Шушы көннәрдә чәчү машиналары да ремонтланып бетә.

Укучы балалар атларны тәрбияләү өчен шефка алдылар. Алар атларның туйдырылган һәм вакытында эчертелгән булуын көн саен күзәтеп торалар. Ябык атлар ялга куелды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

17 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштагы районда безнең частьлар дошманның берничә контратакасын кире кайтардылар. Н-че часть сугышчылары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, көчле рәвештә ныгытылган өч терәк пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. 400 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 9 танк, 3 бронемашина, алты көпшәле 3 миномет, пулеметлар, автоматлар, винтовкалар һәм башка хәрби милекләр бар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта гитлерчылар, Н-че частьның алга баруына тоткарлык ясарга омтылып, контратакага ике батальон пехота һәм 20 танк җибәрделәр. Артиллерия һәм бронебойщиклар уты белән немецларның 7 танкысы һәм 11 автомашинасы зарарланды һәм яндырылды. Бик каты сугышта безнең подразделениеләр 400 гә якын гитлерчыларны кырдылар. Халык яши торган икенче бер пункт районында 3 сугыш припаслары склады, 27 автомашина, 2 радиостанция, бик күп киемнәр һәм азык склады кулга төшерелде.

* * *

Украина партизаннарының Сумы өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отряды берничә уңышлы сугыш операциясе үткәргән. Партизаннар, халык яши торган бер зур пунктта немецлар гарнизонына һөҗүм итеп, 60 немец солдатын, полиция начальнигын, старостаны һәм 21 полицейскийны үтергәннәр. Шул ук отрядның бер группа партизаннары дошманның әһәмиятле коммуникациясендәге бер тимер юл күперен шартлатканнар.

18 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

18 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеждан** көньяктарак, **Төньяк Кавказда**, **Донның** түбәнге агымы һәм **Төньяк Донец** районында элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец фашистларының чолганып алынган гаскәрләрен кыруны дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Сугыш нәтиҗәсендә 1.000 нән артык гитлерчы юк ителде һәм 850 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 20 самолет, 38 танк, 91 орудие, алты көпшәле 14 миномет, 1.000 нән артык винтовка һәм автоматлар, 93 пулемет, 20.000 снаряд, 21 радиостанция һәм башка төрле сугыш милекләре бар.

* * *

Воронеждан көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне җәелдерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Дошманның көчле рәвештә ныгытылган бер терәк пункты өчен булган сугышларда иптәш Хорошко командалыгындагы сугышчылар немецларның бөтен гарнизонын диярлек кырып бетерделәр. Халык яши торган икенче бер зур пунктны алган чакта безнең частьлар 1.255 немец солдатын һәм офицерларын, шул исәптән бер полковникны плен алдылар.

* * *

Төньяк Донец районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Бер участокта совет сугышчылары, омтылышлы удар ясап, немецларны халык яши торган өч пункттан бәреп чыгардылар. Бер батальонга якын немец пехотасы кырып ташланды, дошманның 7 танкысы зарарланды һәм яндырылды, 20 орудие юк ителде. 300 кеше плен алынды. 2 танк, 20 орудие, 50 автомашина һәм төрле сугыш снаряжениесе тутырылган 2 склад кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказда совет частьлары халык яши торган берничә пунктны һәм ике тимер юл станциясен алдылар. Халык яши торган бер зур пунктның көнбатыш читендә бик каты сугышлар бара. Безнең сугышчылар, дошман позицияләренә каршы көчле артиллерия әзерлеге алып барганнан соң, инженерлык ныгытмаларын һәм мина кырларын үттеләр һәм немецларның каршылык күрсәтүен җиңеп, бу пунктның читләренә бәреп керделәр. Урам сугышларында 450 гитлерчы юк ителде, 5 танк, 13 автомашина зарарланды һәм яндырылды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта гвардияче кавалеристлар, чигенүче дошманны куып барып, дошманның бер рота пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

Смоленск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Һәлакәт нәтиҗәсендә 8 цистерна янган. 13 платформа һәм төрле йөкләр төялгән 4 вагон җимерелгән. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары бер күперне һәм тимер юлны шартлатканнар, 1.000 метр озынлыкта телефон-телеграф линиясен кисеп алганнар.

* * *

Совет гаскәрләренең Великие Луки шәһәрен алулары гитлерчылар арасында буталыш һәм чуалыш китереп чыгарган. Германия командованиесе, немецлар армиясенең бу зур җиңелүен яшерергә маташып, 3 нче январьдан башлап, һәркөнне, Великие Луки шәһәре элеккечә немецлар кулында дип күрәләтә ялган хәбәрләр игълан итә. Шушы көннәрдә Германиянең информация бюросы, немецларның «зур танк берләшмәләре Великие Лукига барып чыга алдылар һәм Великие Луки гарнизоны шактый күп ярдәмче көчләр һәм кораллар алды» дип хәбәр итте. Берлинда бу ахмак һәм ялган әкиятләрне төзеп яткан арада гитлерчылар командованиесе Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак һәм төньяк-көнбатыштарак удар группировка туплады һәм шәһәрне яңадан алыр өчен бөтен көче белән маташып карады. Немецларның исәбе бик гади иде: совет гаскәрләренең Великие Лукины алуларын һәркөнне бик тырышып инкар итәргә, ә шул арада, берничә корбаннар белән дә хисаплашып тормастан, шәһәргә таба үтеп чыгарга һәм аны алырга. Шулай итеп, гитлерчылар бер ату белән ике куянны үтерергә теләделәр: беренчедән, гаять зур әһәмияте булган бу шәһәрне яңадан алырга; икенчедән, үзләренең бик нык какшап киткән дәрәҗәләрен төзәтергә.

Немецлар, көч туплаганнан соң, Великие Лукидан көньяк көнбатыштарак һәм төньяк көнбатыштарак бик каты контратакалар ясадылар. Ләкин совет командованиесе немецларның планын сизеп алды һәм кирәкле чараларны вакытында күрде. Безнең гаскәрләр, өзлексез ударлар ясап, дошманны хәлсезләндерделәр һәм аны гаять зур югалтуларга дучар иттеләр. Немецларның һөҗүме аларның үз каннарына батты. Шулай итеп, немецлар группировкасы үзенең алдына куйган максатына ирешә алмады, ә Великие Луки шәһәре 1943 нче елның 1 нче январеннан бирле һәрвакыт совет кулында булды һәм хәзер дә аның кулында. Великие Луки янында Гитлерның чираттагы авантюрасы немецлар өчен әнә шулай күңелсез төстә бетте. Гитлерчылар командованиесе исә үзенең ахмак ялганчылар шайкасы икәнлеген бөтен дөньяга тагын һәм тагын бер кат күрсәтте.

18 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Ладога күленнән көньяктарак урнашкан безнең гаскәрләр Ленинград шәһәрен чолгап алган немец-фашист гаскәрләренә каршы шушы көннәрдә һөҗүмгә күчтеләр. Безнең гаскәрләр, дошманның озак вакытка исәпләп ясалган ныгытылган полосасын эчкәрегә таба 14 километрга кадәр өзеп һәм Нева елгасын кичеп, каты сугышларның 7 көне эчендә, дошманның гадәттән тыш каты каршылык күрсәтүен җиңеп, **Шлиссельбург** шәһәрен, ныгытылган зур пунктлардан **Марьинны**, **Московская Дубровканы**, Липканы, 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7; 8 нче номерлы эшчеләр поселокларын, **Синявино** станциясен һәм **Подгорная** станциясен алдылар.

Шулай итеп, 7 көн дәвам иткән сугышлардан соң Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре 18 нче январьда бергә кушылдылар һәм шуның белән Ленинград блокадасын өзделәр.

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре **Төньяк Донец** елгасын кичтеләр, тимер юл станциясе **Каменскины** алдылар һәм **Каменск** шәһәрендә сугышлар алып баралар. Безнең гаскәрләр **Ново-Псков** район үзәген, халык яши торган күп кенә зур пунктларны, шул исәптән **Ново-Беленькаяны, Донцовканы, Лебедьне, Рыбаковны, Краснодонецкаяны** алдылар.

Көньяк фронт гаскәрләре **Маныч** елгасын кичтеләр һәм **Дивное** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, халык яши торган пунктлардан **Привольныйны, Ремонтныйны, Мокрая Ельмутаны, Нижний Серебряковны** алдылар.

Воронеж фронты гаскәрләре тимер юл станциясе **Каменканы**, халык яши торган күп кенә зур пунктларны, шул исәптән **Истобноены, Россошьны, Хмелевоены, Афанасьевканы, Карпенковоны** алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр **Черкесск** шәһәрен, тимер юл станциясе **Баталпашинскины**, халык яши торган зур пунктлардан **Суркульны, Красноярскийны** һәм башкаларны алдылар.

* * *

18 нче январьда безнең авиация частьлар фронтның төрле участокларында немецларның 30 га якын танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 300 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар; 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 3 сугыш припаслары складын һәм 2 ягулык складын шартлаттылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец-фашист гаскәрләрне чолгап алган боҗраны кысуларында дәвам итәләр. Көнбатыштан хәрәкәт итүче совет частьлары сугыша-сугыша алга киттеләр. Шәһәрдә безнең сугышчылар берничә урамны һәм дошманның терәк пунктларын алдылар. Бер тимер юл тармагы янында аеруча каты сугышлар булды. Анда дошман, үзенең ныгытмаларына таянып, бик каты каршылык күрсәтә. Тулы булмаган саннар буенча, безнең гаскәрләр 2.000 гитлерчыны юк иттеләр, 400 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар. Трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеждан көньяктарак совет гаскәрләре уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман, техникасын һәм бик күп сугыш милекләрен ташлап чигенә. Ольховатка-Шалякино юлы участогында безнең частьлар 1.000 нән артык төзек автомашина кулга төшерделәр. Россошь шәһәрендә немецларның 10 танкысы, 79 орудиесе, 560 автомашинасы, 33 мотоцикл, 13 азык склады, 10 артиллерия склады, 7 ягулык склады, медицина милекләре тутырылган 5 склады, 200.000 артиллерия снаряды, бер миллион чамасы патроны кулга төшерелде. 1.855 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды. Безнең частьлар, алга таба барып, халык яши торган уннарча пунктларны немец-фашист оккупантлардан азат иттеләр.

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман бик нык каршылык күрсәтә һәм оборона өчен уңайлы булган һәрбер чиккә тотынып калырга тырыша. Бер участокта немецлар контратакага шактый күп пехота көчләре һәм 30 танк җибәрделәр. Совет частьларының ударлары астында гитлерчылар күп югалтуларга дучар булдылар һәм ашыгыч рәвештә чигенделәр. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм дошманның 4 танкысын, 9 орудиесен, 25 автомашинасын һәм бер рота пехотасын юк иттеләр.

Төньяк Донец районында Н-че берләшмә частьлары немецларны кысрыклауны дәвам иттерделәр. Бик каты сугышта дошманның 8 танкысы, 9 орудиесе юк ителде һәм бик күп дошман солдатлары һәм офицерлары кырылды. Бер сугыш припаслары склады, 3 корал склады һәм 2 азык склады кулга төшерелде. Лейтенант Губинның танк экипажы бик кызу тизлек белән дошман кулындагы бер пунктка бәреп керде, немецлар арасында паника тудырды, бер рота немец пехотасын таркатты һәм бер өлешен танкысы белән таптатып юк итте, 20 орудиене сафтан чыгарды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга киттеләр һәм Черкесск шәһәрен, шулай ук халык яши торган берничә зур пунктны алдылар. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышларда Н-че часть немецларның бер батальон пехотасын тар-мар итте, дошманның 6 танкысын һәм 15 автомашинасын зарарлады һәм яндырды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Карел-Фин ССР ның вакытлыча оккупацияләнгән территориясендә хәрәкәт итүче партизан отрядлары берничә уңышлы операция үткәргәннәр. «Полярники» отряды дошманның фронт линиясенә бара торган бер эшелонын юлдан чыгарган. Бер паровоз, сугыш припаслары һәм азык төялгән 10 вагон җимерелгән. Январь башында «Большевик Заполярья» һәм «Советский Мурман» отрядлары немецларның һәм акфиннарның зур җәза отрядына каршы сугышлар алып барганнар. Карательләрнең партизаннарны чолгап алырга һәм юк итәргә маташулары барысында җимерелгән. Совет патриотлары 38 гитлерчыны үтергәннәр һәм берничә дистә гитлерчыны яралаганнар. «Вперед» исемле партизаннар отряды дошманның азык һәм почта төялгән обозын туздырган. Обозның сакчылары үтерелгән. Күп азык һәм хәрби почта кулга төшерелгән.

* * *

Франциянең азат укчылары Пуатье районында немецларның бер складына һөҗүм иткәннәр. Патриотлар немец сакчыларын үтереп бетергәннәр. 12 пулемет, 28 автомат, берничә йөз кул гранатасы кулга төшергәннәр һәм качып киткәннәр. Сен-Поль якынында азат укчылар немецларның поездларын бәрелдерүне оештырганнар. Һәлакәт вакытында 50 дән артык гитлерчы үлгән.

С

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 15 нче ЯНВАРЕНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	95,7	38. Юдино	46,7	75. Иске Тимошкино	28,1
2. Нөркәй	94,3	39. Дөбьяз	45,8	76 Буденный	28,1
3. Чокалы	89,1	40. Актаныш	45,5	77. Балык бистәсе	28,0
4. Ишеево	80,0	41. Кукмара	44,6	78. Арча	27,9
5. Тымытык	75,7	42. Куйбышев	43,9	79. Черемуховский	27,8
6. Бөгелмә	74,5	43. Тәтеш	43,7	80. Чалпы	27,0
7. Чүпрәле	74,4	44. Т. Тамак	43,6	81. Константиновка	26,9
8. Тирсә	72,5	45. Иске Чишмә	40,9	82. Аксубай	26,8
9. Саба	68,0	46. Буа	40,7	83. Рождественский	26,6
10. Алабуга	65,9	47. Баулы	40,7	84. Әтнә	26,0
11. Тархан	63,9	48. Исәнбай	40,5	85. Стоблище	25,9
12. Норлат	61,9	49. Бондюг	40,0	86. Биектау	25,0
13. Юртыш	60,7	50. Димитров	40,0	87. Тәкәнеш	24,5
14. Яниль	59,1	51. Б. Матак	39,2	88. Кызыл юл	24,4
15. Кызыл йолдыз	58,3	52 Зирекле	38,4	89. Чишмә	24,2
16. Мөрәле	57,4	53. Акташ	37,9	90. Ро[illegible]дан	24,1
17. Зөя	57,1	54. Тельман	37,7	91. Сәлман	23,7
18. Кадряк	56,8	55. Яңа Чишмә	37,3	92. Чаллы	23,6
19. Сарман	56,6	56. Иске Писмән	35,0	93. Каргалы	23,3
20. Заинский	55,2	57. Теләче	34,7	94. Трехозерский	22,6
21. Октябрь	55,2	58. Питрәч	34,0	95. Минзәлә	21,7
22. Алга	55,0	59. К. Тамагы	33,3	96. Майлан	20,7
23. Беренче Май	54,9	60. Кәкре елга	32,8	97. Кузнечиха	20,6
24. Соколка	54,9	61. Биләр	31,7	98. Әлки	14,3
25. Чистай	54,9	62. Әхмәт	31,4	99. Тат. Ходяш	12,5
26. Азин	54 8	63. Морт	31,4	100. Тат. Ялтан	12,1
27. Кузайкино	54 5	64. Маткавыш	31,0	101. Үзәк	11,8
28. Дәүләки	54,3	65. Алексеевский	30,4	102. Чиябаш	11,1
29. Поповка	53,7	66. Казанбаш	30,3	103. Кошкино	10,9
30. Кызыл Чапчак	53,6	67. Шөгер	30,2	104. Ключи	10,3
31. Олы Кариле	52 0	68. Калинин	30,0	105. Мамадыш	8,2
32. Чыбыклы	61,1	69. Солтан	29,4	106. Зур Поляна	7,0
33. Әлмәт	50 0	70. Карамалы	29,1		
34. Мөслим (Чистай)	50,0	71. Балтач	28,8		
35. Ютазы	48,0	72. Әлши	28,6	Барлыгы:	39,6
36. Мәлки	48,0	73. Кичү	28,6	1943 нче елның	
37. Чүрибураш	46,8	74. Макыл	28,3	10 нчы январена	37,

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

ПФ 827 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 117